# “Мин татарча сөйләшәм”

К.С. Фәтхуллова, КФУ доценты; Г.Ә. Нәбиуллина КФУ доценты

Мәкалә 10-04-29407а/В / 2010 (РГНФ) номерлы грант кысаларында язылды

“Татарстан Республикасы халыкларының телләре турындагы” Закон кабул ителгәннән соң, икетеллелекне тормышка ашыру өлкәсендә шактый эшләр башкарылды. Бу закон, беренче чиратта, республикабызда яшәүче һәр кешенең - татармы ул, русмы әллә башка милләттәнме, татар телен гамәли белүен таләп итә.

Татар телен чын мәгънәдә дәүләт теле дәрәҗәсенә җиткерү җиңел эш түгел. Шулай да бу өлкәдә ирешелгән уңышлар турында әйтеп үтәргә кирәк дип саныйбыз: мәктәп һәм югары уку йортларында татар телен укыту өчен, махсус программалар, дәреслекләр һәм методик кулланмалар төзелеп бастырылды; күпсанлы сүзлекләр, сөйләүлекләр, үзөйрәткечләр дөнья күрде. Даими рәвештә дәүләт оешмаларының хезмәткәрләрен татар теленә өйрәтү курслары оештырыла; фәнни-гамәли конференцияләрдә, түгәрәк өстәлләрдә татар телен өйрәтү методикасының актуаль мәсьәләләре, укытучыларның алдынгы тәҗрибәсе төрле яклап яктыртылып тора. Шунысы куанычлы: махсус тикшеренүләр күрсәткәнчә, республика халкының 50 процenttан артыгы ике телдә сөйләшә ала.

Телгә өйрәтүне исә, балалар бакчаларыннан, мәктәпләрдән үк башларга кирәклеге шик уятмый. Алга таба югары уку йортларында татар телен өйрәнү мәҗбүри булырга тиеш. Димәк, бу эшкә татар теленә өйрәтү методикасын белгән тәҗрибәле белгечләрне тарту, шулай ук яңа уку-укыту кулланмаларын әзерләү һәм гамәлгә кертү мөһим. Бүгенге көндә татар теле Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты, Казан дәүләт финанас-икътисад институты, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты, Казан дәүләт техника университеты, Казан дәүләт технология институты,

Казан дәүләт аграр университеты, Казан дәүләт медицина университетында укытыла.

Татар халкының милли мәдәниятен, телен, әдәбиятын, тарихын өйрәнү, үстерү белән беррәттән, телебезне рус һәм чит ил вәкилләренә өйрәтүдә Казан федераль университетының да тәҗрибәсе зур.

Тарихны искә төшерсәк, фәнни мәктәпләре белән дан тоткан университетта бу юнәлештә эш XIX гасыр башында зур үсеш алган була. Танылган галимнәр С. Хәлфин, А.М. Казембек, Ф.Эрдман, И. Березин, И.Хәлфин, Ш. Мәрҗәни, К.Насыйри, М. Корбангалиевлар татар телен, татар тарихын өйрәнүдә зур тырышлык күрсәтәләр. 1944 нче елда татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылганнан соң, әлеге өлкәдә эшчәнлек эзлекле, максатчан юнәлеш ала. Заман сулышына, рухи-мәдәни кыйммәтләр үзгәрешенә, милли яңарыш хәрәкәтенә җавап йөзеннән 1989 нчы елда татар филологиясе һәм тарихы факультеты оеша. Җәмгыятьтәге үзгәртеп кору җилләре 1992 нче елда Казан университетында татар теленә өйрәтү кафедрасы ачылу өчен кирәкле шартлар тудыра, соңрак кафедраның исеме гамәли тел белеме һәм тәрҗемәчелек кафедрасы итеп үзгәртелә. Инде егерме елга якын әлеге кафедра Казан университетында рус телле студентлар белән беррәттән чит ил вәкилләренә дә татар теленә өйрәтү кебек җаваплы эшне башкара. Чын мәгънәсендә, кафедра татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую, ныгыту, күтәрү максатларына хезмәт итә, дияргә мөмкин. Бу эшчәнлек Татарстан-Яңа гасыр телерадиокомпаниясендә һәм вакытлы матбугатта кафедра укытучылар биргән интервью-язмаларда һәрдаим яктыртылып бара.

Гомер-гомергә Россиядә тюркология бишеге булып торган Казан университетында бүгенге көндә дөньяның төрле почмакларыннан килгән чит ил студентлары, аспирантлары татар телен өйрәнәләр. Германиядән килгән Гиссен һәм Азат университеты студентлары (ДААД программасы нигезендә)

университетта берничә ел дәверендә стажировка үтеләр. Шулай ук төрле илләрнең югары уку йортларында белем алучы филологлар, тарихчылар, икътисадчылар, политологлар һәм шул исәптән, эшкуарлар, композиторлар, экологлар һ.б. татар телен өйрәнү яки белемнәрен тирәнәйтү максаты белән кафедрага мөрәҗәгать итәләр.

Татар теле белән кызыксынучы алман галимнәреннән беренчеләрдән булып Берлиндагы Азат университетының Тюркология институтыннан докторлар Маргарете Эрсен-Раш, Хайретдин-бей Сейхан, Элиф Дилмачны искә алып үтәсе килә. Шулай ук Рин Смит (США, 1992/1993); Майл Трид (Великобритания, 1993/1994); Сесиль Дрисе (Швейцария, 1995/1996); Дженатан Янг, Карл Браун, Айрекс (США, 1997/1998); Мон Кит Чинг (Гонконг, 1997/1998); Катрин Нили, Фрэнк Ямрик (Нью Йорк, 1998/1999); Тим и Мелиса Бентли (Южная Каролина, 1998/1999); Исакова Синсукэ (Япония, 2000/2001); Фатьма Сахан (Турция, 2000/2001); Холл Дарен, Энди Кокчна, Эрик Страчан (США, 2000/2001); Рауль Матика, Иоханнес Циммерман (Германия, 2001/2002); Джеймс Майер, Ричард Фитцморес, Даниэль Росс, Мадина Гольберг (США, 2002/2003); Режан Лебреттон (Париж, 2002/2003); Норихиро Наганава (Япония, Токио, 2002/2003); Майя (Германия, 2002/2003); Джеймс Майер, Синтия Каплан (США, 2003/2004); Нилгон Коя (Германия, 2003/2004); Джеймс Хансон (США, 2003/2004); Наталья Ангер- Лагос, Скотт Леглер, Кайл Маркварт (США, Аризона, 2005/2006); Со Ун Ми, Ли Сунын (Корея, 2007/2008); Масуми Исакай (Япония, Кобэ, 2007/2008); Акира Сакурама (Япония, 2008/2009); Брендон Шехтер, Метью Депп (США, 2008/2009); Марк (Турция, 2009/2010); Тимо Классен (Голландия, 2009/2010); Аврам Лион (США, Калифорния, 2010/2011) кебек төрле елларда татар телен өйрәнгән шәкертләребезне атап үтәргә мөмкин. Мисаллардан күренгәнчә, кафедрага татар телен өйрәнергә килгән шәхесләрнең географиясе елдан-ел киңәя бара. Шәкертләр арасында Япониялән, Монголиядән, Кореядан, Франциядән, Швейцариядән, Финляндиядән, Испаниядән, Австриядән килгән студентлар да бар. Мондый

кызыксыну бүгенге көндә дә бар. Татар теле белән кызыксынучыларга тел төркемләп яки берәмләп өйрәтелә. Чит илләрдән төрле максатлар белән килүчеләр берничә айдан алып бер-ике ел дәвамында аралышыр-аңлашыр дәрәҗәдә татар телен өйрәнеп китәләр, һәм кабат, Казанга килеп, татар теленә өйрәтү дәресләрен дәвам итәргә ашыгалар. Чит ил студентларыннан алынган сораштырулар, анкеталар, хатлар әнә шуны күрсәтә. Калифорния университеты профессоры Сентия Каплан, мәсәлән, Казан университетына татар теле өйрәнергә өч тапкыр килә (2004, 2006, 2008 елларда). Казанга берничә тапкыр килүен профессор болай дип аңлата: *”Я изучила в общей сложности шесть языков. Таким образом, я приношу опытную критическую перспективу к языковому исследованию. Само собой разумеется, я не возвратилась бы для языкового исследования в Казанском государственном университете, если бы я не чувствовала, что это было высшего качества... Я сейчас знаю место, чтобы изучить язык…. Мое изучение татарского языка на кафедре обеспечило невероятно важную способность проникновения в суть не только татарского языка, но и татарской культуры, за что я очень благодарна. Рекомендую эти языковые курсы серьезным ученым за пределами Татарстана. Без знания татарского языка невозможно серьезно понять татарскую историю, культуру, общество“.* Сер түгел, чит ил вәкилләре безнекеләргә караганда күпкә тырышлар, алар, үз максатларына ирешү өчен, бар көчләрен биреп укыйлар.

Татар теленә өйрәтү дәресләре аңлы-коммуникатив методның төп нигезләмәләрен күздә тотып алып барыла: лексик-грамматик берәмлекләрне сайлауга һәм өйрәтүгә функциональ якын килү; лексик-грамматик материалны концентрик рәвештә урнаштыру һәм этаплап өйрәтү; тел һәм сөйләм материалын ситуатив-тематик һәм синтаксик нигездә өйрәтү һ.б. Укыту чараларына килгәндә, дәресләр кафедра укытучыларының бу өлкәдә озак еллар дәвамында тупланган фәнни-методик тәҗрибәсенә таянып төзелгән дәреслек-кулланмалар нигезендә алып барыла. Шунысын

ассызыклап үтәргә кирәк: икенче телгә өйрәтү, иң беренче чиратта, шушы телдә аралашу, сөйләшү-аңлашу күнекмәләрен булдыруны күз алдында тота.

Шуңа күрә дә уку-укыту эшчәнлегенең төп максаты студентларның сөйләм телен һәм аралашу осталыгын үстерү белән билгеләнә. Чит ил кешеләрен татар теленә өйрәтү «Татарский язык. Интенсивный курс» дәреслеге нигезендә алып барылды. Укытучылар өчен Ф.С.Сафиуллинаның “Татар теленә өйрәтүнең фәнни-методик нигезләре” исемле хезмәте методик ярдәмгә килсә, студентлар исә, үз чиратында, төрле сүзлекләр, кулланмалардан файдалана ала: «Татарско-русский фразеологический словарь», «Карманный татарско-русский и русско-татарский словарь», «Татарский на каждый день» Самоучитель. Инглиз телле укучылар өчен кафедра галимнәре тарафыннан төзелгән «The tatar language. Intensive course bay F.S.Safiullina, K.S.Fatcullova (Kasan: Heter. 2002. — 233 s.) дәреслеге күп еллар дәвамында чит илләрдә дә кулланылышта булды. Мәсәлән, Американың Аризона университетында, Парижның Көнчыгыш цивилизацияләре һәм теллләре институтында һ.б. Бүгенге көндә кафедра укытучылары тырышлыгы белән чит ил студентлары өчен махсус дәреслек “Татар теле - күңелем теле” (Авторлары - К.С. Фәтхуллова. Ә.Ш.Юсупова, Э.Н.Денмөхәммәтова. Тәрҗемәче-редактор Д.Р. Шәрифуллина) укыту комплекты төзелде. Ул дәреслектән һәм аудиокушымтадан тора. Чит ил студентларын татар теленә интенсив рәвештә өйрәтү максатыннан чыгып төзелгән әлеге укыту чарасы ярдәмендә татар теленнән башлангыч белем бирергә һәм аларны беренче баскыч дәрәҗәсенә куелган халыкара таләпләргә әзерләргә мөмкин.

Татарстанның башкаласына килгән чит ил кешеләре татар телен өйрәнү белән беррәттән, татар халкының мәдәнияте, сәнгате, гореф-гадәтләре, милли ашлары турында мәгълүмат алып китәләр. Аларга, берничә сәгать күләмендә генә булса да, татар халкының теле, аның үзенчәлекләре, тел сәясәтенә бәйле проблемалар, Татарстан Республикасындагы башка халыкларны татар теленә

өйрәтү мәсьәләләре турында мәгълүмат җиткерелә. Кирәк булганда, алар белән тарихчылар, сәнгать белгечләре махсус дәресләр үткәрәләр. Моннан тыш студентларыбыз Казандагы музейлар, театрлар белән танышалар, татар җырчыларының концертларына йөриләр, күргәзмә залларында булалар. Чит ил студентлары массакүләм мәгълүмат чараларында биргән интервью-язмаларында да татар мәдәнияте һәм сәнгатенә зур кызыксыну, хөрмәт уянуын ассызыклыйлар. Татар дуслары белән аралашу, татар гаиләләрендә булу, халкыбызның милли ризыкларын, гореф-гадәтләрен өйрәнергә мөмкинлек бирә. Мондый эшләр студентлар тарафыннан да хуплана. Мәсәлән, Америка студенты Кайл Маркъюардт, үзенең бер хатында рәхмәт хисләрен белдереп, болай дип яза: *“Преподаватели старались не только обучать языку, но и развивать у студентов уважение к татарской культуре, истории и наследию. Такая методика крайне полезна для изучения языка — если преподаватели не знакомят студента с культурным наследием, студент не захочет или не сможет изучать язык».*

Инде нәтиҗә ясап, шуны әйтәсе килә, татарлар үз кабыгында гына бикләнеп ятарга тиеш түгел. Бүгенге глобальләшү шартларында телебезне саклау, үстерү хакында сүз алып барганда, татар телен дөньякүләм аренага чыгару, кулланылыш активлыгын халыкара масштабларда киңәйтү мөмкинлеген истән чыгармаска кирәк. Бу бер яктан, телне өйрәнү, аралашу географиясен үстерсә, икенче яктан, башка милләт вәкилләренең иске стереотип фикерләүләрен юкка чыгара. Алар халкыбызның зур һәм шанлы тарихлы, мәгърифәтле, гаять матур гомумкешелек һәм милли сыйфатларга ия булуларын, мәдәни казанышлары еракка барып тоташа торган халык икәнлеген аңлый башлыйлар. Төрле чит илләрдән килеп татар телен өйрәнүчеләр әйткәнчә, милләтнең телен белмичә, аның җанын да, рухи дөньясын да аңлап булмый һәм, әлбәттә, аның белән үзара хезмәттәшлек, дуслык мөнәсәбәтләре урнаштыру да мөмкин түгел. Шуңа күрә татар телен өйрәнү Татарстанга килгән чит ил кешеләре өчен генә түгел, ә биредә яшәүче барлык милләт вәкилләре өчен дә тормыш ихтыяҗы булсын иде, диясе килә.